**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**егерме сигезенче утырыш**
**КАРАРЫ**

14 июнь 2019 ел **№ 178** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүгә турында Нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2010 елның 7 маендагы 10/13-09/2179 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы муниципаль Хезмәт кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүгә турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Теләче муниципаль районы Советының социаль-икътисадый үсеш буенча комитетына йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы И.Ф. Зарипов

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Советының
2019 елның «14» июненнщн
178 нче номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе турында
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге Нигезләмә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта (алга таба – мәҗбүри дәүләт иминияте) муниципаль хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе буенча түләүләр очракларын, тәртибен һәм күләмнәрен билгели.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең гомере һәм сәламәтлеге муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән көннән алып, муниципаль хезмәткәр вазыйфасыннан азат ителгән көнгә кадәр мәҗбүри дәүләт иминиятенә алынырга тиеш.

3. Муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт узучы җирле үзидарә органнары һәм башка муниципаль органнар мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминиятләүчеләр (алга таба-иминиятләүчеләр) булып тора.

4. Мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминиятләүчеләр (алга таба - иминиятләүчеләр) мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыруга лицензияләре булган иминият оешмалары булырга мөмкин.

Иминиятләүчеләрне сайлап алу дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5. Иминият килешүе иминиятләүче һәм иминиятләштерелүче арасында иминиятләштерелгән зат файдасына (файда алучы) бер календарь елга, бер тәүлеккә 24 сәгать дәвамында иминият яклавы белән, Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә төзелә.

Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән иминият очраклары өчен иминиятләүче тарафыннан иминият килешүендә файда алучылар даирәсе билгеләнә.

Иминият килешүендә файда алучылар буларак мәҗбүри рәвештә исемнәре аталырга тиеш:

иминиятләштерелгән затның үлем көненә аның белән теркәлгән никахта булган ире (хатыны);

иминиятләштерелгән затның ата - анасы (уллыкка алучылар), иминиятләштерелгән затның ата-анасы булмаган очракта, әби-бабасы, әгәр алар аны өч елдан да ким булмаган вакыт тәрбияләгән булсалар;

иминиятләштерелгән затның үги анасы һәм үги атасы - аны биш елдан да ким булмаган вакыт тәрбияләгән очракта;

иминиятләштерелгән затның 18 яшькә җитмәгән яки аннан өлкәнрәк булган балалары, әгәр алар 18 яшькә кадәр инвалид булсалар, шулай ук оештыру-хокукый

формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә мәгариф оешмаларында белем алучы һәм укуны тәмамлаганчы, әмма 23 яшькә җиткәнче балалар;

иминиятләштерелгән зат карамагындагылар.

Файда алучылар иминият килешүендә граждан хезмәткәрләренә аларны иминиятләштерүче билгеләгән тәртиптә бирелә торган мәгълүмат нигезендә күрсәтелә. Иминият килешүендә файда алучы күрсәтелмәгән очракта, файда алучы булып, гражданнар законнарында билгеләнгән тәртиптә, иминиятләштерелгән зат варислары таныла.

6. Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәт вазыйфасыннан төзелгән иминият килешүенең срогы чыкканчы азат итү муниципаль хезмәткәргә карата иминият килешүенең эшчәнлеген муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгән көннән туктатуга китерә. Күрсәтелгән нигез буенча муниципаль хезмәткәргә карата иминият килешүе вакытыннан алда туктатылган очракта, иминиятләүче әлеге муниципаль хезмәткәрне иминиятләштерүгә бәйле рәвештә иминият премиясен муниципаль хезмәткәргә карата иминият килешүенең гамәлдә булу вакытына пропорциональ калган өлешен әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында билгеләнгән тәртиптә кире кайтара.

7. Иминият очраклары булып тора:

1) иминиятләштерелгән затның муниципаль хезмәт үткән чорда үлеме, шулай ук муниципаль хезмәт үткән чорда алынган имгәнүләр һәм авырулар аркасында муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә үлеме;

2) муниципаль хезмәт үткән чорда иминиятләштерелгән затка инвалидлык билгеләү, шулай ук муниципаль хезмәт үткән чорда имгәнүләр яисә авыру аркасында муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә билгеләү;

3) муниципаль хезмәт үтү вакытында иминиятләштерелгән зат тарафыннан имгәнү яисә травма алу;

4) иминиятләштерелгән затның эшкә алучы вәкиле инициативасы буенча хезмәт контрактын өзү өчен муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәткәр вазыйфасыннан азат итү һәм сәламәтлеге буенча медицина бәяләмәсе нигезендә муниципаль хезмәттән азат итү һәм инвалидлык билгеләү белән бәйле булмаган авыру алуы.

8. Иминиятләштерелгән затларга (файда алучыларга) түләнә торган иминият суммаларының күләме муниципаль хезмәткәрнең үзенә йөкләнгән вазыйфасы нигезендә вазыйфаи хезмәт хакыннан һәм муниципаль хезмәткәрнең айлык хезмәт хакын (алга таба – хезмәт хакы) тәшкил иткән класс чиннары өчен айлык өстәмә түләүдән чыгып билгеләнә.

9. Иминият очраклары башланганда иминият суммасы түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

1) муниципаль хезмәт үткән чорда иминиятләштерелгән зат үлгән очракта, шулай ук муниципаль хезмәт узу чорында алынган имгәнүләр, травмалар һәм авырулар аркасында муниципаль хезмәт итүдән азат ителгәннән соң бер ел дәвамында - 26,25 хезмәт хакы. Күрсәтелгән иминият суммасы файда алучыларга тигез өлешләрдә түләнә;

2) муниципаль хезмәт үткән чорда, шулай ук муниципаль хезмәт үткән чорда алынган имгәнүләр, травмалар һәм авыру нәтиҗәсендә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә инвалидлык алган иминиятләштерелгән затка:

I төркем инвалидка - 17,5 хезмәт хакы үләмендә;

II төркем инвалидка - 12,25 хезмәт хакы күләмендә;

III төркем инвалидка - 10,5 хезмәт хакы күләмендә;

3) муниципаль хезмәт үткән чорда иминиятләштерелгән зат тарафыннан каты имгәнү яки травма алган очракта - җиде хезмәт хакы, җиңел имгәнү яки җәрәхәт алган очракта - 1,75 хезмәт хакы күләмендә. Имгүнүләр яки травмаларны тиешле иминият суммасы түләнә торган авыр яки җиңел җәрәхәтләргә кертү «Хәрби җыеннарга чакырылган хәрби хезмәткәрләрнең, гражданнарның, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарының гади һәм җитәкче составы, Россия Федерациясенең Янгынга каршы дәүләт хезмәте, җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары хезмәткәрләре, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре хезмәткәрләре гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе турында»гы 1998 елның 28 мартындагы 52 номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән исемлек (яраланулар, травмалар, контузияләр) нигезендә билгеләнә.

4) иминиятләштерелгән затның эшкә алучы вәкиле инициативасы буенча хезмәт контрактын өзү өчен муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәткәр вазыйфасыннан азат итү һәм сәламәтлеге буенча медицина бәяләмәсе нигезендә муниципаль хезмәттән азат итү һәм инвалидлык билгеләү белән бәйле булмаган авыру алуы – 8,75 хезмәт хакы.

Әгәр муниципаль хезмәт үткән чорда, йә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер елга кадәр вакыт үтсә, медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесендә яңадан тикшерү үткәрелгәндә иминиятләштерелгән затка инвалидлык төркеме арттырылса, иминият суммасы да яңадан билгеләнгән инвалидлык төркеме буенча исәпләп чыгарылган хезмәт хакы һәм элеккеге инвалидлык төркеме буенча исәпләнгән хезмәт хакы саны арасындагы аерма тәшкил итә торган сумма күләмендә арттырылачак.

Иминият очрагына бәйле рәвештә иминиятләштерелгән затка иминият суммасы түләнгән булса, әмма иминият очрагы килеп чыккан көннән соң ел дәвамында аның белән бәйле рәвештә сәламәтлеге начарланса яки үлем очрагы булса, элек түләнгән иминият суммасын (иминият суммаларын) тотып калып, өстәмә иминият акчасы түләнә.

Иминиятләштерелгән һәр кеше өчен түләнә торган иминият премиясе күләме иминият килешүе белән билгеләнә һәм иминиятләштерелгән затның иминият килешүе төзегән вакытка булган хезмәт хакының 8,75 процентыннан артмаска тиеш.

10. Иминиятләүче мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминият суммасын түләүдән түбәндәге иминият очракларында азат ителә:

1) иминиятләштерелгән зат суд тарафыннан билгеләнгән тәртиптә иҗтимагый куркыныч дип танылган гамәл башкару нәтиҗәсендә;

2) иминиятләштерелгән затның суд тарафыннан билгеләнгән тәртиптә алкоголь, наркотик яки токсик исереклеге белән турыдан-туры бәйлелеге;

3) иминиятләштерелгән затның үз сәламәтлегенә яки үз-үзенә зыян салуы нәтиҗәсендә суд тарафыннан исбатланган сәбәпләр аркасында.

Әгәр иминиятләштерелгән затның үлеме суд тарафыннан исбатланган үз-үзенә кул салу дәрәҗәсенә җиткерү нәтиҗәсе булса, иминиятләүче иминият суммасын түләүдән азат ителми.

Иминият суммасын түләүдән баш тарту турындагы карар иминиятләүче тарафыннан кабул ителә һәм иминиятләштерелгән затка (файда алучыга), иминият суммасын түләүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән срокта, түләүдән баш тарту сәбәпләренең дәлилләгән формада язмача хәбәр ителә.

11. Иминият түләүләре иминиятләүче тарафыннан иминиятләштерелгән затның (файда алучының) гаризасы һәм иминият очрагы килеп чыгуны раслый торган документлар нигезендә башкарыла.

Иминият түләүләрен башкару турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны бирү һәм карау тәртибе иминият килешүе белән билгеләнә.

Иминиятләштерелгән затларга иминият суммаларын түләү иминият килешүләренең башка төрләре буенча тиешле суммаларга бәйсез рәвештә башкарыла.

Иминият суммалары иминият килешүе белән билгеләнгән ысул белән иминиятләштерелгән затларга (файда алучыларга) сумнарда исәпләнгән суммалар күчерү юлы белән түләнә.

Иминият суммасын түләү күрсәтелгән түләү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар алган көннән соң 10 көн эчендә иминиятләүче тарафыннан башкарыла.

12. Әгәр иминият килешүе гамәлдә булу срогы дәвамында иминиятләштерелгән затларның хезмәт хаклары күләмнәре, шулай ук аларның саны үзгәрсә, күрсәтелгән шартларга бәйле рәвештә алынып бетмәгән яки артык алынган иминият кертемнәре суммасы өстәп түләнергә яки кире кайтарылырга тиеш. Иминият килешүе төзегән якларның килешүе буенча күрсәтелгән сумма иминият килешүе гамәлдә булган чираттагы чорга иминият кертемнәре күләмен билгеләгәндә исәпкә алынырга мөмкин.

Иминият кертемнәрен иминиятләүченең кертү вакыты иминият килешүе белән билгеләнә.

13. Мәҗбүри дәүләт иминиятенә чыгымнарны финанслау муниципаль берәмлек бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

---